БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» 11 2020 ел. № 313

«Мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 августындагы 280 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан һәм медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләүне үткәрүне камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 5 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 августындагы 280 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Иҗтимагый совет составына Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хезмәте вазыйфаларын алмаштыручы затлар һәм муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштыручы затлар, шулай ук «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы була алмый торган башка затлар керә алмый».

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (территориаль үсеш буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.С. Галимуллин